КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 август г.Казань № 880

Аерым дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында" 2018 ел, 29 март, 194 нче карары белән расланган тәртиптә билгеләнә торган «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре (алга таба - учреждениеләр) җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен индексацияләргә.

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә учреждениеләр җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләп чыгару өчен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,04 тапкырга индекслаштырырга һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләргә  Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин